ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
М.ХӘСӘНОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ
ҺӘМ ТӨБӘКНЕ ӨЙРӘНҮ ИНСТИТУТЫ
ЭНЦИКЛОПЕДИСТИКА ҮЗӘГЕ

# КАЮМ НАСЫЙРИ:

## ИЛЛЮСТРАЦИЯЛЕ ПЕРСОНАЛЬ ЭНЦИКЛОПЕДИЯ

КАЗАН – 2025

УДК 37(470.41)(092)Насыри
ББК 74.03(2Рос.Тат)-8Насыри я20
Н26

Басма Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
М.Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты
тарафыннан әзерләнде

**Басманың фәнни мөхәрририяте:**
Э.М.Галимова (рәис), Р.В.Шәйдуллин (җаваплы мөхәррир),
Л.М.Айнетдинова, М.Ш.Сибгатуллина, Б.Л.Хәмидуллин

**Каюм Насыйри: иллюстрацияле персональ энциклопедия** / төз.-авт.: Р.В.Шәйдуллин (төркемнең җитәкчесе), Р.Ф.Исламов, Ф.С.Гыйниятуллина, Ф.Г.Камальтдинова, И.Х.Хәлиуллин, Ф.Р.Бәдретдинова, Г.И.Каюмова. — Казан: М.Хәсәнов исем. Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, 2025. — 500 б., ил.

Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулуга багышланган персональ энциклопедиядә бөек татар мәгърифәтчесенең фәнни хезмәтләре, педагогик эшчәнлеге, әдәби иҗаты, шулай ук татар халкының аның тарафыннан фәнни нигездә өйрәнелә башлаган этнографиясе һәм фольклоры турында мәгълүматлар тупланган. К.Насыйри татар әдәби теленә нигез салган, аның грамматикасын һәм лексикографиясен системалаштырган, мәктәпләр өчен дәреслекләр язган, үзенең календарьлары, фәнни хезмәтләре һәм әдәби иҗаты белән татар халкының аң-белемен үстерүгә, милли мәдәниятен саклауга биниһая өлеш керткән мәгърифәтче галим буларак күрсәтелә. Шулай ук аның тәрҗемәи хәле һәм иҗаты фәнни өйрәнелгән хезмәтләр яктыртыла.

Бу хезмәтне төзүнең төп максаты — К.Насыйриның күпкырлы иҗатын энциклопедик кысаларда туплап, киң даирә укучыга, аеруча милләтебезнең яңа буыннарына җиткерү һәм аның фәнни-мәдәни мирасын саклауга ярдәм итү.

**УДК 37(470.41)(092)Насыри**
**ББК 74.03(2Рос.Тат)-8Насыри я20**

ISBN 978-5-902375-88-3

© Аерымланган структур берәмлек «ТР Фәннәр академиясенең М.Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты», 2025

# КЕРЕШ

2025 елда татар халкы күренекле мәгърифәтче, язучы һәм энциклопедист галим Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулу уңаеннан әлеге зур вакыйганы билгеләп үтә.

Мәгълүм булганча, бөек мәгърифәтче үзенең күпкырлы хезмәте белән татар халкын, аның телен, мәдәниятен, фәнни казанышларын дөньякүләм танытуга зур өлеш кертә. Ул — халыкның бай рухи мирасын җыеп, аны төрле яклап өйрәнеп, эшкәртеп, китаплары һәм календарьлары аша башкаларны да таныштырган, татар халкының данын күтәрүгә барлык көчен куйган олпат шәхес. Мәгърифәтченең үз милләтенә олы мәхәббәт хисе белән сугарылган фәнни, иҗади, наширлек һәм педагогик эшчәнлеге халыкның аң-белемен баетуга, аны милли-мәдәни агартуга юнәлдерелә.

Мәртәбәле вакыйга уңаеннан татар халкы тарихында һәм мәдәниятендә Каюм Насыйрига багышланган беренче персональ энциклопедия нәшер ителү Татарстан халыклары тормышында истә калырлык зур вакыйга булыр дип ышанам. Энциклопедияне кулына алган һәркем аның сәхифәләре аша мәгърифәтче шәхесенең зурлыгына, аның гыйльми-нәзари кызыксынуларының киңлегенә тирәнрәк төшенер, үзе өчен яңа ачышлар ясар, галимнең тәрҗемәи хәле белән танышканда, ул яшәгән һәм иҗат иткән дәвер, халыкның тормыш-көнкүреше турында күзаллау булдырыр, мәгърифәтченең эшчәнлек һәм аралашу даирәсе аша төрле милләт зыялылары турында күп мәгълүмат алыр. Аның фәнни һәм иҗади сәләте, милли-мәдәни карашлары, халкының рухи көч-куәтенә ышаныч хисләре беркемне дә битараф калдырмас дип уйлыйм.

Әлеге саллы хезмәт Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең М.Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты тарафыннан әзерләнде. Аны татар милли мәдәниятенең үткәнен — бүгенге белән, бүгенгене — киләчәк белән тоташтыручы күпер дип әйтергә мөмкин. Хәзинәгә тиң бу энциклопедик басма безне алга таба да изге, игелекле эшләргә генә рухландырып торыр, яңадан-яңа казанышларга көч бирер, халкыбыз мирасын киләчәк буыннарга төкми-чәчми тапшырырга ярдәм итәр.

Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулуны билгеләп үтү турында махсус фәрман имзалаган Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н.Миңнехановка, «Каюм Насыйри: иллюстрацияле персональ энциклопедия»сен гамәлгә куюга зур ярдәм күрсәткән ТР Дәүләт Советы рәисе урынбасары, ТР Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе М.Г.Әхмәтовка, шулай ук төрле фән тармаклары галимнәренә, музей һәм китапханә хезмәткәрләренә, төбәк җитәкчеләренә, мөгаллимнәргә һәм әлеге басмага хезмәте кергән һәркемгә мөхәрририят исеменнән тирәнтен зур рәхмәтемне белдерәм.

*Э.М.Галимова,*
*Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты директоры,*
*сәнгать фәннәре кандидаты, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе,*
*РФнең һәм ТРның Композиторлар берлеге әгъзасы, РФнең һәм ТРның Театр эшлеклеләре берлеге әгъзасы, М.Җәлил исемендәге Республика бүләге лауреаты*

## УКУЧЫЛАР ИГЪТИБАРЫНА

Бер томлы Каюм Насыйри энциклопедиясе — татар халкы тарихында һәм мәдәниятендә К.Насыйриның тәрҗемәи хәленә һәм күпкырлы эшчәнлегенә багышланган беренче персональ энциклопедия. Әлеге энциклопедиянең төзелүе һәм нәшер ителүе К.Насыйриның тууына 200 ел тулуның татар халкының фәнни-мәдәни тормышында зур вакыйга буларак билгеләп үтелүе белән бәйле.

К.Насыйриның гасыр ярымнан артык вакыт эчендә төрле җыентыкларда, аерым китап-календарьларында тупланган, беркадәре әле хәзер дә кулъязма хәлендә саклаучы фәнни хезмәтләре һәм әдәби мирасына, ачышуңышларына, аларның әһәмиятенә гомуми йомгак-нәтиҗә ясау, галимнең тәрҗемәи хәлен, фәнни һәм иҗади юлын, яшәгән мохит-даирәсен, тормышына һәм эшчәнлегенә зур йогынты ясаган шәхесләрне мөмкин булган кадәр төгәллек белән ачыклау, фәнни-гамәли иҗатының төрле өлкәләрендә аның энциклопедист галим һәм татар мәгърифәтчесе буларак чагылышын системага салып барлау вакыты да җиткән иде.

2023 елның 22 мартында Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н.Миңнехановның «Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулуны бәйрәм итү турында»гы Указы киң җәмәгатьчелеккә җиткерелү белән, ТР Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты Каюм Насыйри энциклопедиясен төзү турында тәкъдим белән чыкты. Әлеге гаять әһәмиятле мөмкинчелектән файдаланып, институтның Энциклопедистика үзәгеннән бер төркем галимнәр һәм фәнни хезмәткәрләр бу эшкә алынырга батырчылык итте. Проектның җитәкчесе тарих фәннәре докторы, профессор Рафаил Шәйдуллин, моңа кадәр дөнья күргән берничә Россия һәм Белоруссия персональ энциклопедияләре, шул исәптән Габдулла Тукай һәм Салават Юлаев энциклопедияләре белән танышып чыгып, алардагы безнең энциклопедияләргә дә хас һәм күп кенә үзенчәлекле якларны үрнәк итеп алып, басманың гомуми концепциясен, структурасын эшләде. Персональ энциклопедия өчен җаваплы төркем (Р.Ф.Исламов, Ф.Р.Бәдретдинова, Ф.С.Гыйниятуллина, Ф.Г.Камальтдинова, Г.И.Каюмова, И.Х.Хәлиуллин) энциклопедиядә урын алырга тиеш дип уйланылган мәкалә һәм белешмәләрнең исемлеген төзеп эшкә кереште.

Персональ энциклопедия тугыз тематик юнәлешкә караган, һәрберсе татар дөньясында уникаль К.Насыйри феноменын, аның күпкырлы фәнни-гамәли эшчәнлеген ачуга хезмәт итә алырлык дип фаразланган мәкалә һәм белешмәләрне үз эченә ала.

Беренче тематик юнәлеш мәгърифәтченең үзе исән вакытта дөнья күргән һәр китабына һәм рус телендә язылган берничә мәкаләсенә фәнни-нәзари күзлектән шәрехләнгән, темасы, проблематикасы, эчтәлеге, басмалары (шул исәптән сайланма әсәрләре) һәм башка хосусиятләре тикшерелгән энциклопедик белешмәләрдән тора.

Икенче тематик юнәлештә К.Насыйриның еллык календарьлары проблематик планда карала. Һәр календарьда аның тарафыннан бастырылган мәкаләләрнең, бер-берсе белән кабатланмыйча, кыскача эчтәлеге күрсәтелә.

Өченче тематик юнәлештә, иҗтимагый-сәяси һәм милли-дини мәсьәләләр белән бәйләнештә, К.Насыйриның руханилар уку йортларында, рус-татар мәктәбендә укытуы гомуми һәм проблематик планда карала, ягъни аның фикерләү үзенчәлекләре, педагогик алымнары, шулай ук дини-әхлакый карашлары игътибар үзәгенә куела, халыкчанлык, миллилек һәм башка мәсьәләләр тикшерелә.

Дүртенче тематик юнәлештә сүз мәгърифәтченең нәсел-тамыры, туганнары, танышлары, замандашлары (галимнәр, әдипләр, аның хакында хатирәләр язучылар һ.б.), укучылары турында бара. Әлеге юнәлештәге мәкаләләр һәм белешмәләр өчен төп чыганаклар булып К.Насыйриның үз нәселе турындагы язмалары, мәгърифәтче хакында авылдашлары һәм аның белән турыдан-туры яки хезмәтләре аша таныш булган замандашлары язып калдырган истәлекләр, китапханә, архив, музей фондларында саклана торган документлар һәм иллюстратив материаллар хезмәт итә.

Бишенче тематик юнәлештә сүз К.Насыйриның татар тел белеме, әдәбияты, фольклоры, тарихы, этнографиясе һәм гомумтабигыять гыйлеме өлкәләрендәге эшчәнлеген аерым мәкаләләрдә күрсәтү, үзенчәлекле фикер-карашларын яктырту мәсьәләләре хакында бара.

Алтынчы тематик юнәлешкә К.Насыйриның тәрҗемәи хәлен һәм күпкырлы фәнни-гамәли иҗатын өйрәнүгә һәм барлауга үз өлешен керткән татар, рус һәм башка милләт галимнәренең эшчәнлеге яктыртылган белешмәләр керә. Алар Шәрекъ һәм Европа әдәбияты, шулай ук татар халык авыз иҗаты үрнәкләренең бәрәкәтле тәэсирен тойган К.Насыйриның язма һәм гамәли мирасын өйрәнүгә багышланган материаллардан гыйбарәт. Мәгърифәтченең дүрт томлы сайланма әсәрләре басылып чыкса да, әле дә байтак хезмәтләре (шул исәптән календарьларындагы мәкаләләр) гамәлдәге татар язуына күчерелмәгән. Шул сәбәпле, аның иҗатын энциклопедия кысаларында бар тулылыгында чагылдыру мөмкинлеге булмады. Биредә шулай ук мәгърифәтченең тормышы һәм иҗаты белән бәйле Гыйльми үзәк чаралары, аның юбилей даталарына бәйләп нәшер ителгән җыентык материаллары, төрле фәнни-гамәли форумнар чагылыш таба.

Җиденче тематик юнәлештәге мәкаләләрдә К.Насыйри шәхесе һәм иҗатының татар мәдәниятенең төрле юнәлешләрендә — сынлы сәнгатьтә (портретлар һәм бюстлар), театр һәм әдәбиятта (драматургия, проза, шигърият) яктыртылышы тикшерелә.

Сигезенче тематик юнәлештәге мәкалә һәм белешмәләрдә К.Насыйри тормышы белән бәйле урыннар: Казан губернасының аның иҗатында чагылыш тапкан Зөя өязе авыллары (шул исәптән, Югары Шырдан (хәзер Кече Шырдан), Олы Ачасыр, Бәчек, Күгеш һ.б.), Казан шәһәре, Сәгыйд бистәсе, Мәкәрҗә ярминкәсе һ.б., ул яшәгән йортлар, укыган мәдрәсәләр, эш урыннары; шулай ук Казандагы, Яшел Үзән районындагы аңа багышланган музейлар, аның исемен йөрткән институт, мәктәп, урам һ.б. турында мәгълүмат бирелә.

Тугызынчы тематик юнәлештәге мәкаләләрдә ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреатларының (аерым шәхесләр һәм коллективлар) эшчәнлеге яктыртыла.

Кушымтада ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреатлары исемлеге, шулай ук К.Насыйриның Казан федераль университеты Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең кулъязма һәм сирәк китаплар бүлеге һәм ТР Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге фондларында сакланган хезмәтләре, кулъязмалары һәм аңа кагылышлы материаллар исемлеге (таблицаларда) китерелә.

Әлеге энциклопедистик басманың структур һәм композицион төзелешенә килгәндә, ул К.Насыйриның тормыш юлы һәм эшчәнлегенә гомуми күзәтү ясалган күләмле мәкаләдән башлана. Әлеге текст мәгълүмат эзләүне җиңеләйтү максатыннан төп тексттан аермалы шрифтта җыелган һәм сылтамалар белән тәэмин ителгән. Энциклопедиянең төп өлешендә мәкаләләр һәм белешмәләр алфавит тәртибендә урнаштырылган. Энциклопедистиканың «түгәрәк буенча уку» принцибыннан чыгып, мәкаләләрнең шактый өлеше сылтамалар һәм өлешчә сылтама-мәкаләләр белән ныгытылган. Шулай ук кайбер очракларда (мәсәлән, аерым мәкаләләрне кушымталар белән бәйләү өчен) гиперсылтамалар да бирелгән.

Мәкалә ахырында чыганаклар, әсәрләр һәм әдәбият исемлеге урнаштырылган. «*Әсәр.*:» дигәндә, К.Насыйриның үз әсәрләре һәм башка авторларның басмалары күрсәтелә; «*Хезм.*:» дигәндә, мәкалә авторының үз хезмәтләре китерелә. Әсәрләр һәм хезмәтләр хронологик тәртиптә урнаштырыла, аларда авторның исем-фамилиясе күрсәтелми. «*Чыг.*:» төшенчәсе теге яки бу мәкаләне язганда файдаланылган хезмәтләрне күздә тота һәм чыганак авторының исеме күрсәтелә. «*Әд.*:» өлешендә теге яки бу мәкаләне язганда кулланылган хезмәтләр исемлеге татарча басмалардан башлап (аннары рус һәм чит телләрдә) бирелә, авторның исеме куела.

Кайбер аббревиатураларны (СССР, КПСС һ.б.) исәпкә алмаганда, Каюм Насыйри энциклопедиясендә шартлы кыскартылмалар юк диярлек.

Әлеге энциклопедиядә, өстәмә һәм күрсәтмә мәгълүмат чыганагы буларак, төрле иллюстратив материал урнаштырыла. Иллюстрацияләрне басмага әзерләүчеләр: Г.Р.Дәүләтьянова, Р.Н.Шакиров; дизайнер: Ф.Ә.Ибраһимова, китапны компьютерда биткә салучылар: Р.Р.Сәләхиев,

А.Б.Насибуллина. Энциклопедияне төзү һәм редакцияләү эше башлыча ТР Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты хезмәткәрләре тарафыннан башкарылды.

Әдәби һәм фәнни җәмәгатьчелекне, гомумән, киң катлау укучыларны Каюм Насыйри энциклопедиясе төзүнең эш барышы белән таныштырып тору максатында Р.В.Шәйдуллин, Р.Ф.Исламов, Ф.Р.Бәдретдинова, Ф.С.Гыйниятуллина, Ф.Г.Камальтдинова, Г.И.Каюмова, А.Б.Насибуллина, Р.Р.Сәләхиев, И.Х.Хәлиуллин һәм башка авторлар вакытлы матбугатта чыгыш ясыйлар, фәнни-гамәли конференцияләрдә катнашалар, язмаларын фәнни, фәнни-популяр җыентыкларда бастыралар. Персональ энциклопедиянең фәнни-методик нигезләре һәм контент мәсьәләләре Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтында 2024 елның апрелендә махсус уздырылган «Каюм Насыйри персональ энциклопедиясенең текст һәм иллюстрацияләр контентлары икърар ителешенең фәнни-методик үзенчәлекләре» түгәрәк өстәлендә һәм башка форумнарда каралды.

Китапның ахырында институт директоры Э.М.Галимова мөхәрририят исеменнән әлеге күләмле һәм җитди хезмәтне гамәлгә куюга ярдәм күрсәткән дәүләт эшлеклеләренә, галимнәргә, музей һәм китапханә хезмәткәрләренә, төбәк җитәкчеләренә, педагогларга һәм башкаларга олы рәхмәтен белдерде (тулырак кара кушымтаны: *Рәхмәт сүзе*).

*Мөхәррирдән*



## КАЮМ НАСЫЙРИ
## (1825–1902)

**КАЮМ НАСЫЙРИ** (Насыйри Габделкаюм Габденнасыйр улы), мәгърифәтче, фольклорчы, этнограф, нашир; хәзерге татар әдәби теленә нигез салучы, җыеп әйткәндә, энциклопедист галим. 1825 елның 14 (искечә — 2) февралендә Казан губернасының Зөя өязе (хәзер Татарстанның Яшел Үзән районы) Югары Шырдан (хәзер *Кече Шырдан*) авылында рухани гаиләсендә дөньяга килә.

К.Насыйри — күпкырлы фәнни һәм наширлек, мәдәни-агарту эшчәнлеге белән исемен татар халкына гына түгел, бөтен дөньяга таныткан шәхес. Татар һәм рус зыялылары аны юкка гына «татар Ломоносовы», «татар Леонардо да Винчие» дип зурламагандыр. Ул — гомере буе халкына фидакарьләрчә хезмәт иткән, милләт мәнфәгатен үзенең яшәү кыйбласына әверелдергән татар галимнәренең берсе. К.Насыйри соңгы көннәренә кадәр мәгърифәт юлындагы эшчәнлеген ташламый. «Үзегез карт, күзләрегез зәгыйфь булса да, язуыгызны дәвам итәсез икән» диючеләргә ул: «Алла мине язар өчен яраткан, бу көннән язмый утыру аның хөкеменә каршылык булыр дип куркам», — дип җавап бирә торган була.

***Нәселе.*** Каюм Насыйри борынгы ыруга карый, аның нәсел башы Казан ханлыгы чорында ук Иделнең уңъяк ярында Болгарстан ягыннан килеп төпләнгән Бираш исемле кешегә барып тоташа. «Җиденче буынга кадәр» бабалары барысы да укымышлы кешеләр булган. К.Насыйриның бабасы Хөсәен Мукаев (1760–?) атасы Әлмөхәммәттән яхшы дини тәрбия һәм белем ала. Әлмөхәммәт улы Хөсәен күп еллар Югары Шырдан авылында имам булып тора. Коръәнне ким дигәндә 100 тапкыр күчереп яза, нәхүне (синтаксис) яхшы белә. К.Насыйриның кайбер мәгълүматларына караганда, бабасы «Шәрхе мелла» (грамматика буенча), «Мисбах» (дин нигезләре буенча), «Сарыф һәваи» (синтаксис буенча) исемле китаплар яза. Аның өч улы була: Габденнасыйр, Мөхәммәтгалим һәм Хөснетдин. Каюмның атасы Габденнасыйр *Хөсәенов* берничә телне, шул исәптән гарәп, фарсы, рус телләрен яхшы белә. Авылдашларының киңәшчесе сыйфатындагы ышанычлы кеше була. Коръән гыйлемен сәламәт практицизм белән берләштереп, ике дөньяны — илаһият һәм җир тормышын тигез күреп яши. Хәлле гаилә башлыгы була. Г.Хөсәенов улларын да сәләтләренә карап укыта, шул рәвешчә аларны олы тормышка әзерли (тулырак кара: *Насыйрилар нәселе*).

Габденнасыйрның башка угылларыннан аермалы буларак, К.Насыйри, нигездә, фәнни-агарту эшчәнлеге белән шөгыльләнсә дә, аңарда эшмәкәрлек сәләте дә күзәтелә. Китапларын бастыру һәм сату өчен үз басмаханәсен һәм китап сату фирмасын булдырырга тырышып карый. Егерме елдан артык вакыт дәвамында бастырып чыгарган календарьлары гына да — шуның ачык мисалы. Мәгърифәтче аларны төзеп кенә калмый, үзе рәсемнәр һәм карталар да ясый, үз акчасына бастыра, тарату һәм сату белән шөгыльләнә, кергән керемгә яңа календарьлар һәм хезмәтләр нәшер итә. Татар галимнәре арасында беренчеләрдән булып, китапларны сату өчен билгеле бер уңайлылык тудырган реклама рәвешендәге *«Игъланат»* басмасын чыгара. Галим, нигездә, китап сату, укыту һәм өстәмә эшчәнлекләреннән кергән акчага яши. Васыятеннән күренгәнчә, мохтаҗлыкта гомер кичерми (кара: *«Васыятьнамә»*).

***Уку-укыту еллары.*** Буыннан-буынга килгән гыйлем-мәгърифәткә омтылыш К.Насыйриның киләчәген алдан ук билгеләп куя сыман. Башлангыч белемне әтисе мәктәбендә алганнан соң, 1841 елда Казанга *«Касыймия»* мәдрәсәсенә укырга китә. Ул чорда мәдрәсәләрдә белем бирү сыйфаты *Татарстан Республикасы Дәүләт архивында* саклананган документларда ачык күренә. Мәсәлән, Казан шәһәренең Россия Халык мәгарифе министрлыгына буйсынмаган мөселман мәктәпләре турында 1854 елгы ведомостьта мәдрәсәдә өйрәнелгән фәннәрнең исемлеге бирелгән. Әлеге мәгълүматларга күз салсак, бу дәвердә гарәп, фарсы, төрек һәм башка телләрдә уку һәм язу; күпмедер дәрәҗәдә Коръәннән дә белемнәр бирү һәм арифметика кагыйдәләрен татар телендә өйрәтү каралган булуы аңлашыла. Шәрекъ телләрен белү мөселман Якын Көнчыгышы илләре фәне һәм мәдәнияте белән танышу өчен зур мөмкинлекләр ача. Шул чор шәкерте буларак,

К.Насыйри да телләр өйрәнүгә һәвәс була, мәдрәсәдә укыганда ул гарәп, фарсы, төрек телләрен өйрәнә, рус телен мөстәкыйль рәвештә үзләштерә, шушы телләрдәге әдәбиятлар белән якыннан таныша. 1855 елда «Касыймия»не пишкадәм таныклыгы белән, ягъни «бишле» билгеләренә генә тәмамлый. Мондый таныклык аңа мулла яки, мәдрәсәдә кече мөгаллим булып, шәкертләр укыту хокукы бирә.

1855 елда К.Насыйри *Казан өяз руханилар училищесы* ректоры протоиерей Ираклий Лепоринский тәкъдиме белән анда татар теле дәресләре укыта башлый. Укыту елларында аның тормышында шәркыятьче галим, Казан руханилар академиясе профессоры Г.С.*Саблуков* зур роль уйный. Аның тәкъдиме белән К.Насыйри *Казан руханилар семинариясенә* укытучы итеп билгеләнә. Ул анда укучыларга татар теле грамматикасын, татар телендә Инҗилне һәм татарча сөйләм телен өйрәтә. Аның ярдәмендә гамәли класс семинаристлары фигыль һәм исемнәрне төрләндерергә, сүзләргә грамматик анализ ясарга өйрәнәләр. К.Насыйриның мөгаллимлек эшенә җитди каравының нәтиҗәсе буларак, семинария укчылары арасыннан да галимнәр чыга: шуларның берсе — П.П.*Масловский*. К.Насыйри руханилар семинариясендә укытучылык эшчәнлеге өчен 1857–1858 елларда айга 8 сум 33 тиен хезмәт хакы ала, аның чардагының бер бүлмәсендә яши. Мөгаллимлек эшчәнлегеннән тыш, К.Насыйри татар теле сүзлекләре һәм *грамматикасы* төзү белән дә шөгыльләнә. Аның Казан руханилар семинариясендә эшләгән елларында рус телен өйрәнүче татарлар һәм татар телен өйрәнүче руслар өчен чыгарылган «Кыскача татар нәхүе» (1860) — тел белеменә караган беренче фәнни казанышы. Мәгърифәтченең әлеге хезмәте белән танышып чыккан әдәбият галиме Габдрахман *Сәгъди 35* яшьлек К.Насыйрины өлгереп җиткән алдынгы филолог һәм татар тел белгече буларак бәяли.

Руханилар уку йортларында озак еллар эшләү дәверендә рус укытучылары белән тыгыз элемтәдә тору, алар белән даими аралашу аның рус мәдәнияте белән кызыксынуын тагын да арттыра. Нәтиҗәдә, Россиядә яшәүче татарлар үз иленең тарихын, мәдәниятен һәм туган теле белән беррәттән рус телен дә белергә тиеш дип санаган К.Насыйри 1871 елда татар, башкорт һәм кыргыз мәктәпләре инспекторы В.В.*Радлов* тәкъдиме белән татар балаларына рус теле нигезләрен өйрәтү өчен Казанда беренче башлагыч мәктәп ача һәм укыту эшчәнлеген *татар-рус мәктәбендә* дәвам итә. Әмма әлеге эшләрне башкару өчен шартлар җиңел булмый, бина табу, балаларны укуга тарту өчен бик күп тырышлык куярга, төрле авырлыклар кичерергә туры килә. Өстәвенә Казандагы татар мәдрәсәләренә рус телендә белем бирүче мөгаллимнәрне җәлеп итү күпчелек татарлар арасында ризасызлык уята. Бу мәсьәләдә аеруча иске карашлы муллалар, дин әһелләре җитди каршылык күрсәтә, алар арасында русчаның файдасына караганда, зыяны күбрәк дип санаучылар бихисап була. Шиһабетдин *Мәрҗани*, Хөсәен Фәезханов, К.Насыйри башка бер милләтнең кул астында яшәгән татар халкына рус телен өйрәнү, һичшиксез, кирәк дип саныйлар, патша хөкүмә-

тенә уку-укыту, мәдәни, дини һәм иҗтимагый-икътисади мәнфәгатьләр мәсьәләсендә мөрәҗәгать итү мөһимлеге килеп туа калса да, шулай ук аралашу өчен дә рус теленең кирәклеген яклап чыгалар. Шук ук вакытта алар татар телен, татар халкының гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерү, татарча сүзләр арасына русча сүзләр катыштырып сөйләшүдән саклану тиешлеген катгый итеп куялар.

К.Насыйри, үз дәвере уку-укыту торышының заманча булмавын аңлап, аны үзгәртергә, камилләштерергә омтыла. Россиядәге фәннәрне һәм һөнәрләрне өйрәнү өчен татарларның рус телен белүе шарт дип саный. Шәхси мәктәбендә дә яңа дөньяви фәннәр кертергә, булганнарын үзгәртеп төзергә кирәк дип таба. Үзенең дә русчасы яхшы булган К.Насыйриның рус мөгаллимнәре белән аралашуы, аларны зурлавы кадимче муллаларда нәфрәт уята, алар аның рус-татар мәктәбендә укытуын дини яктан зәгыйфьлеге белән аңлаталар. Дингә аркаланып, гади халыкны кадимчелеккә тарткан, күзләрен томалаган муллалар һәм аларга ышанган татарлар мәгърифәтченең заманча, европача укытуына каршы чыгалар. Шул сәбәпле 1876 елда К.Насыйри әлеге мәктәптәге укыту эшен туктатырга мәҗбүр була. Моңа бәхетсезлек очрагы да килеп кушыла: мәгърифәтче эшләгән иске уку йортының черегән идәне җимерелеп, ул тирән чокырга егылып төшә һәм чак кына суга батып үлми кала. Әлеге фаҗигале вакыйгадан соң, шулай ук карагруһчыларның даими тискәре йогынтысы аркасында тирән нерв киеренкелеге кичергән мәгърифәтче озак дәвалана һәм мәктәпкә кире кайтмаска була.

К.Насыйри еллар дәвамында тупланган педагогик тәҗрибәсен шәхси мәктәбендә һәм татар шәкертләренә уку әсбаплары әзерләүдә киң куллана. Ул алга таба да, өйдә укыту эшчәнлеген дәвам итү максатыннан 1876 елның 3 июлендә Оренбург Мөселман Диния нәзарәтендә уңышлы гына имтиханнар тапшырып, имам-хатип һәм мөдәррис исеменә лаек була. Шул ук елда ачылган *Казан татар укытучылар мәктәбендә* укыту эшен берничә ел дәвам итә. Бу уку йортыннан соң да ул мәгърифәт эшчәнлеген бөтенләй үк ташлап бетерми, кайбер татар эшмәкәрләре һәм зыялыларының балаларына хосусый дәресләр бирә.

К.Насыйри *«Хисаплык»*, *«Гыйльме һәндәсә»*, *«Осуле җәгърәфияи кәбир»* кебек уку әсбапларын төзегәндә, балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, татар телендә фәнни терминология дә эшли. Аның *арифметикага* керткән күп кенә сүзләре татар әдәби теленә ныклап кереп киткән һәм математика дәреслекләрендә хәзер дә кулланыла (мәсәлән, сан, жыю, алу, бүлү, калдык һ.б.). Арифметика, геометрия, *география*, *ботаника* һәм башка фәннәр буенча хезмәтләре белән К.Насыйри татар яшьләренә дөньяви белемнәргә киң юл ачып кына калмый, аларга фәнни юнәлештә алга таба эшләү өчен ныклы җирлек тә әзерли. Татар мәктәп-мәдрәсәләрендә урта гасырлардан яшәп килгән ятлаулар урынына ул уку-укыту системасында җанлы атмосфера тудыруны, күрсәтмә ысуллар кертүне тәкъдим итә. Теге яки бу фәнне өйрәткәндә, укучыларның танып белү активлыгын стимул-

лаштыру максатыннан дәресләрдә мавыктыргыч ситуацияләр тудыруга, төрле фәннәр буенча белемнәрне тормыштан алынган мисаллар белән ныгытуга өстенлек бирә, бер системага салынган күнегүләр кертә. Шулай ук ул тел, аны укыту мәсьәләләре хакында да мөһим генә фикерләр әйтә, татар теле дәресләрен халык авыз иҗатыннан һәм тормыштан алынган кызыклы мисаллар белән бәйләп укытуны яклап чыга.

***Фәнни-гамәли һәм наширлек эшчәнлеге***. К.Насыйри гомере буе белем туплый, өйрәнә, фәнни-гамәли эшчәнлек алып бара. Ул төрле фәннәрдән хәбәрдар була. Аның рәсем ясау, сызым, китап төпләү, табиплык, балта һәм тимер эшләре белән шөгыльләнүе дә мәгълүм. Петербург университеты профессоры, шәркыятьче галим В.В.*Григорьев* 1880 елда ук инде К.Насыйриның гаять белемле кеше булуы хакында язып чыга. «Мин, татарлар арасында мондый кеше булыр дип һич уйламый идем», — ди галим. Мәгърифәтче Казан университеты белән шактый тыгыз элемтәдә тора. Казан руханилар семинариясендә эшләгәндә, университетка иреклe тыңлаучы буларак лекцияләргә йөри. 1885 елда Казан университеты янындагы *Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең* гыйльми әгъзасы итеп сайлана.

1879 елда К.Насыйри рәсми уку йортларында даими эшләвен туктата һәм калган гомерен язучылык, тәрҗемәчелек һәм фәнни-тикшеренү эшләренә багышлый. Мәгълүм булганча, аның фәнни эшчәнлеге 1855 елдан башланып китә. Бу елда аны Казан өяз руханилар училищесына татар теле укытучысы итеп чакыралар. Алдында торган төп бурычларның берсе буларак, ул татар телен мөмкин кадәр яхшырак өйрәтү тиешлеген аңлап эш итә. Аңа кадәр дә татар теле төрле уку йортларында укытыла, Казан университетында да предмет буларак аерым өйрәнелә. К.Насыйри университет тәҗрибәләрен дә үзләштерә, татар җанлы сөйләм телен өйрәнүгә зур игътибар бирә. Бу аның шул чордагы тел белеменә караган хезмәтләреннән дә аңлашыла. Шул ук вакытта мәгърифәтче иске татар әдәби телен дә кире какмый. Аның фәнни карашлары формалаша һәм торган саен ныгый. Ул Шәрекъ филологиясе гыйлеме өйрәтмәләренә нигезләнгән фикер йөртүдән берникадәр читләшә, Европа мәгърифәтче галимнәре йогынтысында барлыкка килгән һәм үсеш алган европача метод һәм методологияләргә күчеш этабын нәтиҗәле уза.

Мәгълүм булганча, К.Насыйри — хәзерге татар әдәби теленә нигез салучыларның, татар тел гыйлемен яңа фәнни баскычка күтәрүчеләрнең берсе. Аның югарыда искә алынган «Кыскача татар нәхүе» (1860) дәреслек-кулланмасы — шуның ачык мисалы. Ул — К.Насыйриның тел гыйлемен өйрәтүгә, аның фәнни-гамәли нигезләрен булдыруга никадәр җитди караштa торуын раслаучы хезмәт. Бу уңайдан тел галиме Шиһабетдин *Рамазанов* болай дип яза: «19 йөзнең соңгы яртысына чаклы татар әдәби теленең теоретик нигезләре, сөйләм һәм язу нормалары, стилистик алымнары билгеләнмичә килде. Бу мәсьәләләрне һәм бу идеяләрне беренче буларак Каюм Насыйри күтәреп чыкты. Татар милли әдәби телен нигез-

ләү, аның потенциаль мөмкинлекләрен һәм бик нечкә хасиятләрен ачып бирү, грамматик, орфографик һәм орфоэпик нормаларын кагыйдәләштерү бурычларын тарих Насыйрига йөкләгән». Ул тел белемен өйрәнү эшчәнлегендә үз халкының җанлы сөйләменә, гасырлар дәвамында җыела килгән халык авыз иҗаты ядкәрләренә мөрәҗәгать итә, аларны җыйнап, эшкәртеп, китап итеп чыгара, һәм бу аның язучылык таланты ачылуга да зур этәргеч була.

К.Насыйри татар теленең байлыгы, бөтенлеге һәм камиллеге турында үзе болай яза: «Инде телебезгә игътибар итеп, яхшы тикшереп карасаң, шунысы ачыклана: телебездә булган бәетләр, шигырьләр, мәкальләр, табышмаклар гаять төзек ритмлы һәм рифмалы итеп төзелгәннәр; телебез гарәп һәм фарсы сүзләре катнашында мәгънәне тулы һәм матур бирүдә башка телләрдән һич тә ким түгел. Ләкин шуны да әйтеп китәргә кирәк: телебез, бер дә кузгалмыйча, бер урында утырып калган». Мәгърифәтче татар теленең кагыйдәләрен, үзенчәлекләрен ныклап өйрәнергә, шуның ярдәмендә аны камилләштерергә чакыра. Татар телен кимсетеп караучыларга җавап итеп: «Ялган, яла бу! Без — татарлар, телебез — татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел ул», — ди. Аның фикеренчә, телнең аерым бер кеше яисә милләт тормышында әһәмияте бик зур. «Хәзерге заманда башка милләт халыкларының максаты — телне камилләштерүдер», — ди ул. Үз телеңне камил белү башка телләрне өйрәнү өчен дә төп алшарт булып тора, К.Насыйри да шул фикерне раслый: «Әгәр башка телне өйрәнәсе булсаң, — дип яза мәгърифәтче, — ул вакытта үз телеңнең кагыйдәләрен белү бик кирәк».

Тел — укыту, тәрбия бирүнең, милли үзаңны үстерүнең төп нигезе. Олуг мәгърифәтче шуны яхшы аңлый һәм төп игътибарын телне үстерү һәм камилләштерүгә юнәлтә. Ул татар халкының заманча *тел белемен* һәм аның грамматикасын эшләүгә зур өлеш кертә. Халыкның сөйләмен камилләштерү өчен, ул тел үзенчәлекләрен белергә тырыша, аны язуда дөрес чагылдыру ысулларын эзли, сүзләрнең яңгырашын мөкаммәл тасвирлаучы язу кагыйдәләрен булдыра, шул рәвешчә тел гыйлеме ярдәмендә дөрес сөйләү кагыйдәләрен гамәлгә кертүгә юл ача. К.Насыйри, китапларын татарча язып, төрек, гарәп, рус, фарсы телләреннән күп кенә ядкәрләрне тәрҗемә итеп, татар теленең кулланылыш даирәсен киңәйтә, тел мөмкинлекләрен тагын да арттыра, баета. Хезмәтләренең шактые татар теленә багышланган: *«Кавагыйде кыйраәте русия»* (1890), *«Иршад әл-әхба»* (1901), *«Кавагыйде китабәт»* (1892), *«Әнмузәҗ»* (1895), *«Иҗек»* (1895) һ.б. Бер үк вакытта галим тел белеменең аерым бер тармагы саналган татар лексикографиясен дә яңа биеклеккә күтәрә: татар теленең заманы өчен аерым игътибарга лаек ике томлы аңлатмалы сүзлеген (*«Ләһҗәи татари»*, 1895–1896), рус-татар сүзлекләре («Татарча-русча лөгать китабы» — *«Татарско-русский словарь»*, 1878; «Рус хоруфе һәҗас үзә мөрәттиб лөгать китабы» — *«Полный русско-татарский словарь»*, 1892) төзи (тулырак кара: *Лексикография*).

К.Насыйри бер үк вакытта татар халык авыз иҗатын да өйрәнә. Фәннең әлеге юнәлеше белән кызыксынуы аның татар теле нигезләрен өйрәнү буенча гыйльми эзләнүләре белән тыгыз бәйле. Мәгърифәтченең халык иҗатына мәхәббәте руханилар уку йортларында укытканда ук уяна. Димәк, К.Насыйриның фольклористикага тартылуы очраклы күренеш түгел: аның дөньяга карашы формалашуда, теге яки бу мәсьәләгә мөнәсәбәтле гыйльми фикерләре һәм күзаллаулары барлыкка килүдә, иҗатының халыкчанлык рухында үсеш алуында, аннары европачыл мәгърифәтчелек позицияләренә күчешендә татар теле зур роль уйный. Аның бу өлкәдәге эшчәнлеге, фольклорчы галим Хәмит *Ярми* билгеләп үткәнчә, түбәндәгедән гыйбарәт: беренчедән, ул, татар фольклорын турыдан-туры халыкның үз авызыннан язып ала, җыеп туплаган материалларның иң яхшы үрнәкләрен бастырып чыгаруга зур игътибар бирә; икенчедән, башка халыкларны үз халкының тарихы, тормыш-көнкүреше, дөньяга карашы белән таныштыру максатыннан татар халык авыз иҗаты әсәрләренең иң үзенчәлекләләрен рус телендә бастырып чыгаруга күп көч куя; өченчедән, Көнчыгыш фольклорын җентекле өйрәнеп, аның шактыен татарчага тәрҗемә итеп бастыра.

Халык иҗаты әсәрләрен җыю һәм системага салып бастыру барышында, К.Насыйри аларны билгеле бер жанрларга аера, жанрларга — билгеләмәләр, аерым әсәрләргә искәрмәләр, аңлатмалар бирә. Аңа кадәрге һәм замандаш галимнәрнең (Г.Ваһапов, С.Кукляшев, М.Салихов, Г.Фәезханов, Т.Яхин, Н.Ф.Катанов, В.В.Радлов һ.б.) халык авыз иҗатына багышланган хезмәтләре белән чагыштырганда, аның хезмәтләре, бер яктан, материалның күләме һәм сыйфаты, фольклорның барлык жанрларын да диярлек үз эченә алуы белән аерылып тора. К.Насыйриның Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенә татар фольклоры әсәрләрен тапшыруы уңае белән күренекле төрки телләр галиме Н.Ф.*Катанов* болай дип яза: «Бу көнгә кадәр Казан татарларының халык иҗаты ядкәрләрен җыйнаучылардан берәүнең дә бу хәтле күп мәкальләр һәм җырлар тапшырганы юк иде. Насыйров әфәнде тапшырган материаллар, бөтен гомерен үз халкы арасында үткәреп, аны төрле яклап өйрәнүе сәбәпле, аның үз халкының тормышы һәм теле белән яхшы таныш булуын бик ачык күрсәтә».

Икенче яктан, фольклор әсәрләрен җыю һәм бастыру, аларны әдәби әсәрләрдә, тел белеме, тарихи-этнографик хезмәтләрдә файдаланудан тыш, К.Насыйри халык авыз иҗатының аерым фән буларак өйрәнелә башлавына нигез сала. Халык *җырлары*, *бәетләре*, такмаклары мөстәкыйль гыйлем булырга тиеш дип саный һәм һәркайсын аерым өйрәнә. Дөрес, К.Насыйриның үзе җыйган материалларны фольклор җыентыклары итеп чыгару мөмкинлеге булмый, ләкин ул аларга үзенең аеруча әһәмиятле хезмәтләрендә махсус бүлекләр багышлау җаен таба. Мәсәлән, 1880 елда дөнья күргән *«Кырык бакча»* китабының кырыгынчы бакчасы (бүлеге) — 296 мәкаль, 116 кыска җырны, 1884 елда нәшер ителгән *«Фәвакиһел-җөләса фил-әдә-*

*бият»* җыентыгының кырыгынчы раузасы (бүлеге) 27 табышмак, 117 кыска җыр, 3 бәет, 315 мәкаль һәм әйтемне үз эченә ала. Бу хезмәттә автор һәр жанрга кыскача билгеләмә бирә һәм күпчелек әсәрләрне фәнни шәрехләмәләр белән бастыра. К.Насыйри, фольклор материалларының шактыен русчага тәрҗемә итеп, «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләр»ендә *«Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре»* (1896) исеме белән бастыра. Ул 28 табышмак, 243 мәкаль һәм 145 җырдан гыйбарәт. Шул ук «Хәбәрләр»дә (1900) К.Насыйри П.А.*Поляков* белән берлектә язган «Казан татарларының әкиятләре һәм аларны башка халыкларның әкиятләре белән чагыштыру» хезмәтендә 11 татар халык әкиятен бастыра (тулырак кара: *Әкиятләр*). Хезмәттә татар әкиятләренең башка халыкларның әкиятләре белән охшашлыгы күзәтелә. Бу исә татар мәдәниятенең башка халыклар әдәбияты-мәдәниятеннән бер дә кайтыш булмавын раслый.

К.Насыйриның *«Казан татарларының тормышында ислам дине йогынтысыннан тыш барлыкка килгән ышанулар һәм гореф-гадәтләр»* исемле хезмәте — татар фольклорын өйрәнү тарихында беренче фәнни басма. Аның беренче бүлеге башлыча татар мифологиясенең һәм тылсымлы әкиятләрнең сюжетларын һәм персонажларын классификацияләүдән гыйбарәт. Шунысы да игътибарга лаек: автор, хезмәтнең темасы таләп иткәнчә, мифик затларга характеристика бирү белән генә чикләнми, ә әкиятләрдәге кеше образларын да тәфсилле тасвирлый. Хезмәтнең икенче һәм өченче бүлекләрендә татар халкының күпсанлы *сынамышлары*, *ышанулары*, *ырымнары*, йолалары, им-томнары тирәнтен өйрәнелә. Басманың кереш өлешендә Петербург профессоры В.В.Григорьев аның әһәмияте турында болай дип яза: «Казан татары Каюм Насыйров үзенең бу мәкаләсе белән Казан татарларының ислам кабул иткәннәре аркасында хәзергә кадәр аз сакланып калган борынгы мәҗүси гореф-гадәтләрне тикшерүдә беренче тәҗрибә ясый... Фән ноктасыннан бу — шиксез, бик кызыклы, яхшы ук гыйльми хәзинә бирергә вәгъдә итә торган эш. Бу хакта Каюм Насыйров кебек тикшерүче мөселман татарлары арасында гына түгел, бәлки бөтен ислам дөньясында да чыкканы юк, дисәк, ялгышмаган булырбыз» (тулырак кара: *Мифология*, *Фольклор*).

К.Насыйриның татар фольклористика гыйлемен үстерүдәге төп эшчәнлеге, беренчедән, татар әдәби телен гамәлгә кую белән бәйле булса, икенчедән, халык авыз иҗатын өйрәнү аша аны пропагандалаудан, халкыбызның дөньяга карашын киңәйтергә омтылудан гыйбарәт. Татар халык авыз иҗаты әсәрләрен җыйнау гына да — гаять зур хезмәт, К.Насыйри исә аларны фәнни җирлектә өйрәнеп, билгеле бер системага салып бастырып чыгара. Аның турында татар фольклористикасына гыйльми, җәдиди юнәлеш биреп, аны шул нигездә үстереп җибәргән галим дип әйтергә була. К.Насыйри тарафыннан китерелгән әкиятләр, мәкаль-әйтемнәр, *табышмакларда* һәм татар халык авыз иҗатының башка үрнәкләрендә татар халкының үткен акылы, зирәклеге ярылып ята, тормыш-көнкүрешенең үзенчәлеге чагыла.

Халык авыз иҗаты йогынтысында К.Насыйриның тарихи-иҗтимагый фикерләү сәләте, вакыйгаларны тасвирлау осталыгы формалаша. Татар халык иҗатын барлау, җыйнау һәм тикшерү белән бергә ул *тарих*, *археология* һәм *этнография* буенча да материаллар туплый башлый. Археология, тарих һәм этнография җәмгыятендә эшләгәндә, әлеге җәмгыять белән хезмәттәшлек иткән күренекле шәркыятьче галимнәр И.Ф.*Готвальд*, В.В.Радлов, төрки телләр галиме, этнограф Н.Ф.Катанов, тарихчы Н.А.Фирсов һәм башка галимнәр белән аралашу аңарда тарих фәненә зур кызыксыну уята һәм аны өйрәнүгә көчле этәргеч бирә. Әлеге галимнәр аңа тарихи материалларны җыю һәм тикшерү ысулларын өйрәтәләр, җыелган материалдан дөрес файдалану һәм билгеле бер системага салып өйрәнү тәртибенә төшендерәләр. К.Насыйри алар ярдәме белән татар тарихи дөньясын өйрәнүдә кайбер уңышларга да ирешә. Ул, татарлар арасында беренчеләрдән булып, Россия тарихы буенча китап (*«Зөбдәт мин тәварихи әр-Русь»*, 1890) яза. Шулай ук Россия империясе, шул исәптән Казан губернасы һәм илнең башка төбәкләре турында еллык календарьларында тарихи мәкаләләр бастыра. Алар арасында Казан, Зөя шәһәрләре, татар авыллары хакында тарихи *риваятьләр* дә бар. Ш.Мәрҗанидән аермалы буларак, К.Насыйри тарихны халык күзлегеннән чыгып өйрәнергә-тикшерергә һәм аңлатырга омтыла.

Мөгаллимлек һәм фәнни-гамәли эшчәнлек алып бару белән беррәттән ул татар халкын төрле яктан өйрәнү максаты белән еш кына Казан һәм Зөя тирәсендәге авылларда була. Мәкәрҗә ярминкәсенә, Уфага һәм берничә мәртәбә Мәскәүгә бара. 1893 елның җәендә аның Оренбург шәһәренә һәм *Сәгыйд бистәсенә* сәфәр кылуы билгеле. Бу турыда язылган сәяхәтнамәсе дә бар. Шул сәфәрләре вакытында ул татар тарихы, этнографиясе, археологиясе, *эпиграфикасы* буенча риваятьләр, шәҗәрәләр һәм башка материаллар туплый, аларның бер өлешен календарьларында бастыра.

К.Насыйриның *Казан* тарихына караган язмалары аерым игътибарга лаек. Мәсәлән, бер риваятендә ул 16 йөзнең 1 нче яртыларында яшәгән Шаһгали ханның, Мәскәүгә сатылып, Казан мәмләкәтенә, шул исәптән үз халкына хыянәт итүе, ахыр чиктә татарларның, дәүләтчелектән мәхрүм ителеп, коллыкка төшүе турында яза. Аның Аксак Каратун (Лука Конашевич), Пугачёв яулары хакындагы риваятьләре мәгълүматларга байлыгы белән аерылып тора. К.Насыйри Казан тарихы белән беррәттән Казан губернасы Зөя һәм Цивильск өязләре татар авылларының (Ачасыр, Бакырчы, Борнаш, Борындык, Мамадыш, Мулла Иле, Рәсбуга, Шигали, Югары Ширдан һ.б.) тарихы хакында да мәкаләләр яза. Бу уңайдан ул халык авыз иҗатында сакланган материалларны, каберташ язуларын, төрле шәҗәрәләрне, кулъязма һәм басма китапларны ныклап өйрәнә.

К.Насыйри — татар гыйлеме дөньясында милли этнографияне яңача нигезләп, үстереп җибәргән галим. Аның бу өлкәдәге хезмәтләре аңа кадәрге сәяхәтче галимнәрнең этнографик күзәтүләреннән фәнни гомумиләштерүләренең сыйфатлы булуы, теге яки бу мәсьәләгә этрафлы аңлатма бирер-

гә омтылышы белән аерылып тора. Ул фольклорга этнография фәненең бер тармагы буларак кына карамый, аны аерым фән дәрәҗәсендә өйрәнә. Аның татар этнографиясенә караган хезмәтләрендә халкыбызның тормыш-көнкүреше (йорт-җире, кием-салымы, ашау-эчүе), гореф-гадәтләре (балага исем кушу, бәби туе, яучылау, туй уздыру, матәм һәм башка йолалар) яктыртыла. К.Насыйри, беренчеләрдән булып, ашау-эчү турында *«Иршад әл-әтбиха»* (1894) исемле китап яза. Бу китапта катлаулы ашамлык төрләрен әзерләү ысуллары күрсәтелә, 19 йөз татар аш-су традицияләренең бай, үзенчәлекле тасвирламасы бирелә (тулырак кара: *«Археология материаллары (Зөя өязе авыллары буенча)»*).

К.Насыйри шулай ук, татар халык авыз иҗатыннан, Көнчыгыш һәм рус әдәби әсәрләре тәрҗемәләреннән файдаланып, милли әдәбиятны баета. Тәрҗемәче буларак та, зур уңышларга ирешә. Урта гасырлар Шәрекъ классикасы чәчмә әсәрләрен тәрҗемә иткән вакытта, мәгърифәтче аларның оригиналларын татарчага төгәл күчереп, аерым кыскартулар ясап кына калмый, төп текстка теге яки бу дәрәҗәдә тиешле үзгәрешләр дә кертә. Шул ук вакытта аның тәрҗемәләрендә вакыйга-хәлләрне урыны-урыны белән татар халкының тормыш-көнкүрешенә яраклаштыру да күзәтелә. Тәрҗемә остасы буларак, ул төрек язучысы Зыяддин Сәед Яхъяның күренекле мөселман философы, энциклопедист галим, табип Әбугалисина турындагы «Кәнҗинәи хикмәт» («Хикмәт хәзинәсе», 1865) исемле китабын 1872 елда төрекчәдән татарчага тәрҗемә итә. Аның берничә басмада дөнья күргән *«Әбугалисина кыйссасы»* татар халкының рухи-мәдәни үсешенә, гуманистик тәрбиясенә зур йогынты ясый. 1896 елда К.Насыйриның *«Әфсанәи Гөлрох вә Камәрҗан»* әсәренең тәрҗемәсе басылып чыга. Әсәрдә патша кызы белән шаһзадәнең мәхәббәт тарихы үзәккә алынып яктыртыла. Тәрҗемәченең *«Кырык вәзир кыйссасы»* (1868) әсәрендә төрле вакыйгалар ярдәмендә мисал-дәлилләр белән гаделлекнең тантана итүе чагылдырыла. Шулай ук әдипнең тәрҗемәләре арасында «Кабуснамә» (1881, кара: *«Кабуснамә тәрҗемәсе»*) китабы аерым игътибарга лаек. 1886 елда ул шәркыятьче галимә *Гөлнар ханым* (О.С.Лебедева) тарафыннан русчага тәрҗемә ителеп бастырыла. К.Насыйри әдәби тәрҗемәләрен китап итеп кенә чыгарып калмый, ул аларны төрле әсәрләрендә дә урнаштыра («Тәрбия китабы», «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият», «Кырык бакча» һ.б). Аның халык авыз иҗаты үрнәкләреннән, әдәби әсәрләрдән (хикәяләр, новеллалар, шигырьләр) гыйбарәт энциклопедик характердагы «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» исемле дидактик хезмәте татар әдәбияты тарихында аерым урын алып тора. Тәрҗемә эшчәнлеге белән беррәттән әдип-галим татар әдәбиятын фәнни җирлектә дә өйрәнүен дәвам итә. Әдәби ядкәрләргә, татар язучыларына (Габдерәхим Утыз Имәни, Габделҗәббар Кандалый һ.б.) һәм аларның иҗатларына багышланган хезмәтләрендә фәнни әһәмияткә ия күзәтүләр ясый. Мәсәлән, Г.Кандалый шигырьләренең лирик асылын өйрәнеп, аларның поэтик яктан «яхшы төзелү»ен искәртә... Теге яки бу әдәби әсәрнең структур үзенчәлекләре,

идея-эстетик әһәмияте, тәрбияви кыйммәте, шулай ук әдәбиятның башка мәсьәләләре яктыртылган фәнни хезмәтләре аның әдәбият буенча белем дәрәҗәсен күрсәтә.

К.Насыйри татар халкының белемен үстерү максатында төрле фәнни-популяр хезмәтләр дә тәрҗемә итеп бастыра. Алар арасында «Буш вакытларда укырга сүзләр» (1867) җыентыгы аеруча әһәмияткә ия (кара: *«Буш вакыт»*). Ул аны, рус язучысы һәм педагогы К.Д.Ушинскийның башлангыч сыйныф укучылары өчен рус телендә язылган «Балалар дөньясы» (1861) фәнни-популяр һәм әдәби-педагогик хрестоматиясе мәкаләләрен тәрҗемә итеп, күпмедер кыскартып һәм үзгәрешләр кертеп, сәнгатьчә алым-чаралар белән баетып эшли. Балалар өчен махсус татар телендә язылган, укырга кызыклы итеп төзелгән әлеге китап алга таба да фәнни-әдәби әсәрләр иҗат итүгә юл ачкан тәүге басма булып тора. Ул тулысынча диярлек европачыл җәдиди-мәгърифәтчел карашлар кысасында язылган.

К.Насыйри дин мәсьәләләрендә дә киң карашлы, тәрбиягә багышланган хезмәтләрендә халык рухын, әдәп-әхлак кануннарын яхшы тоеп эш итүче галим буларак сыйфатлана. Моның шулай булуын *«Мәҗмәгу әл-әхбар»* китабы (1859) раслый. Мәгърифәтченең мөселман дине тәгълиматы турында 1859 елда язылган *«Гакаид рисаләсе»* китабы 1867 елда гына дөнья күрә. Аның ислам өйрәтүләренә караган берничә хезмәте (*«Мохтәсар тәварих әнбия...»*, *«Утыз вәгазь»*, *«Җәваһир әл-хикәят»* һ.б.) даими рәвештә нәшер ителә (тулырак кара: *Дини гыйлем*).

К.Насыйри, халык педагогикасына, күптөрле язма чыганакларга нигезләнеп һәм Шәрекъ дөньясының фикер ияләре әсәрләреннән файдаланып, тәрбия һәм әхлак турында хезмәтләр яза. Аларда ул белем-тәрбия бирүнең берлеген һәм дәвамчанлыгын, әхлакый һәм гуманистик тәрбиянең мөһимлеген, акыл һәм тәҗрибәнең үзара тыгыз бәйләнештә булуын яктырта, «Һәрбер нәрсәнең, — ди ул, — чиге бардыр. Әмма гакылның чиге вә соңы юктыр... Гакыл вә тәҗрибә бер-берсенә ярдәмче булмакта җир белән су кебектер. Мәгълүм ки, су белән җир бер-берсеннән башка бер нәрсә дә үстерә алмыйдыр...». Галим фикеренчә, ата-ана, мөгаллим үз-үзләрен тотышлары, кылган гамәлләре белән балага тәрбиялелек үрнәге булып торырга тиеш. «Балалар һәрни күрсә, һәрни кылса, ата-анасыннан күреп кыладыр. Атасында, анасында һичбер кимчелек күрмәй үссен, чөнки баланың табигате шундый ки, күбрәк олугларга иярәдер», — ди ул (шулай ук кара: *Гаилә мөнәсәбәтләре*).

К.Насыйри үзенең хезмәтләрендә тәрбия сабакларын еш кына татар халык авыз иҗатыннан, көндәлек тормыштан гыйбрәтле мисаллар, җанлы сюжетлар аша бирә. Бу исә үгет-нәсыйхәтләрнең үтемлелеген, тәэсирлелеген тагын да арттыра. Ул тәрбия эшендә музыка һәм сүз сәнгатенең әһәмиятенә басым ясый. Аның фикеренчә, җыр-музыка «уй-фикерне саф кылыр, зиһенне нечкәртер, табигатьне (холыкны) йомшартыр, мәрхәмәтлене мактатыр, куркакны баһадирландырыр, саранны юмартландырыр». Икенче бер урында мондый юлларны күрергә мөмкин: «Көйләп укымак яки шигырь

әйтмәк гүзәлләрдән янә гүзәл нәрсәдер». Аның күпкырлы тәрбияви хезмәтләрендә, беренче чиратта, физик яктан сәламәт, көр күңелле, белемле балалар тәрбияләү омтылышы сизелә. *«Әхлак рисаләсе»*нең «Гыйлем вә наданлык» исемле беренче бүлегендә әдип балаларга болай дип мөрәҗәгать итә: «Әй газиз бала, агаһ бул, әдәмгә иң әүвәл бигрәк кирәк вә бигрәк лазем нәрсә гыйлемдер, вә гыйлем дигәнемез белмәгән нәрсәне сорашып белмәктер. Вә наданлык дигәнемез белмәклеге лазем булган нәрсәне белмәссезлектер. Бу наданлык кешене игътибардан чыгара торган нәрсәдер, вә хәйван дәрәҗәсенә кертә торган сыйфаттыр, кайда барса да надан кешенең кадере юктыр!». Шулай ук аның хезмәтләрендә һәм педагогик карашларында балаларга нинди дә булса һөнәр өйрәтү кирәклеге ассызыклана. К.Насыйри яшь буынны гыйлем алу белән бергә нинди дә булса һөнәргә дә өйрәнергә чакыра. Бу уңайдан «Китаб-әт-тәрбия» (1891, кара: *«Тәрбия китабы»*) китабында ул болай дип яза: «Әй җаннарым-угланнарым, нәсихәтне ишетегез — һөнәр үгрәнегез. Дөньяның милкенә вә дәүләтенә ышанырга ярамас... Һөнәр — бер агым судыр, вә ышанычлы дәүләттер, һөнәр иясе әгәр дәүләттән төшсә дә кайгы юк... Әй угыл, син дә һөнәр үгрән, тәрбия үгрән, гыйлем үгрән», яки «Кирәк ниндәен һөнәр булса да һөнәрнең артыгы юк», «һөнәр арттырырга иҗтиһат кыл, чөнки һөнәрсез кешенең беркемгә дә файдасы булмас, бәлки үзенә дә файдасы юк». Мәгърифәтченең әлеге карашлары аның тәрбия системасында төп кыйммәт булып торалар. Ул балаларны акыллы, әдәпле булырга өнди. «Олуглык гакыл белән, әдәп белән, әмма нәсел белән, нәсәп белән түгелдер», «әгәр дә бер адәм белән мөсәхабәт кылсаң, аның гакылына кара, диненә карама. Чөнки аның дине үзенә фәкать, әмма гакылы үзенә һәм сиңадыр» дигән карашлары, тәрбия сабаклары шактый әсәрләрендә әдәби образлар аша чагылдырыла, гыйбрәтле мисаллар, тормышчан сюжетлар ярдәмендә яктыртыла. Бу исә үгет-нәсыйхәтләрнең тәэсирен тагын да арттыра (шулай ук кара: *Балалар әдәбияты*).

Гомумән алганда, К.Насыйри татарларның физик, рухи һәм әхлакый яктан сәламәт, камил булуларын тели, милләтне белемле һәм күркәм гадәтле итәргә омтыла. Эчкечелеккә, тәмәке тартуга һәм башка шундый ямьсез сыйфатларга тискәре мөнәсәбәтен белдерә, бу күренешләрне кешеләрне һәлакәткә илтүче кайгы-хәсрәт чыганагы дип саный: «Эчемлек эчә торган кеше һәрбер чәркәне эчкән саен үзен генә үтермидер, бәлки бөтен нәселен үтерәдер...». Аның еллык календарьларында әлеге проблема үзәккә алынып яктыртыла, үгет-нәсыйхәт характерындагы дистәләгән мәкаләсе дөнья күрә. Ул, татар халкы арасында таралган эчкечелекнең һаман саен артуына борчылып, сигез шигырьдән торган поэма яза, анда исереклек галәмәте белән кылынган төрле затсыз гамәлләр сурәтләнә һәм аларда авторның нәфрәт катыш борчу-сагышы сизелә (кара: *«Исереклек заманы»*).

К.Насыйри халыкны агарту максатында «Таң йолдызы» исемле газета чыгару хыялы белән яши, әмма патша хөкүмәте аңа бу ниятен гамәлгә ашырырга рөхсәт бирми (тулырак кара: *Вакытлы матбугат*). Шулай да

ул халыкка белем-мәгърифәт таратуның башка бер ысулын таба: еллык өстәл календаре (горрәнамә) чыгара башлый. 1871 елдан 1897 елга кадәр нәшер ителгән, татар халкының милли-мәдәни тормышында көтелмәгән һәм зур яңалык булган бу календарьлар даими рәвештә халыкның көндәлек тормышыннан яңалыклар, мөһим тарихи-иҗтимагый хәбәрләр белән таныштыра; аларда шулай ук төрле һөнәрләргә өйрәтә торган язмалар, күңел ачу характерындагы материаллар, әкиятләр, мәкальләр, җырлар, Шәрекъ авторларыннан тәрҗемәләр һәм мәгърифәтченең үз әсәрләреннән өзекләр урын ала. Календарьның беренче чыгарылышында ук К.Насыйри аның ахыргы битләрендә халык өчен әһәмиятле булган «Халык арасында тәҗрибәләр буенча көн вә һава үзгәрүнең галәмәтләре бәянында» исемле сәхифә ача. Анда, татар халкы арасындагы төрле сынамышлардан чыгып, һава торышы, авыл хуҗалыгы һәм өй эшләре, бөртекле ашлыкларның уңу-уңмавы һәм башка күренешләр турында фаразлар китерелә. Шулай ук аларда ашау-эчү, крахмал, серкә (уксус) һ.б.ны әзерләргә, җиләк-җимеш киптерергә, дару үләннәрен дөрес җыярга һәм алар белән дәваланырга һәм башка шуның ише гамәлләр генә өйрәтелеп калмый, татарларның белемен арттыру ниятеннән гуманитар (тел белеме, фольклор, тарих, әдәбият, этнография, демография, хокук һ.б.) һәм табигыять (арифметика, *астрономия*, ботаника, география, *медицина*, физика, химия һ.б.) фәннәренең төрле тармакларына караган мәгълүматлар да бирелә (тулырак кара: *Каюм Насыйри календарьлары*). Шул рәвешчә, чирек гасыр дәвамында чыгып килгән календарьлар татар тормышына билгеле бер дәрәҗәдә уңай йогынты ясый, киң гавамны күздә тотып нәшер ителгән бу басмалар татар зыялылары белән беррәттән гади кешеләр арасында да зур популярлык казана, ул Россия буенча, беренче тапкыр татарлар яши торган төбәкләрдә, аерым экземплярлары Урта Азия һәм Кавказ арты мөселманнары арасында да киң тарала (кара: Әбусуфьян *Акаев*). Галим аларны, нигездә, үз акчасына һәм өлешчә аерым эшмәкәрләрнең иганәләре хисабына чыгара. Алга таба календарьлар җирлегендә татар телендә вакытлы матбугат барлыкка килә.

Гыйльми-әдәби эшчәнлеген мәдрәсәдә укыганда ук башлап җибәргән К.Насыйриның үзе исән чакта татар һәм рус телләрендә төрле күләмдәге 40 лап китабы һәм берничә дистә мәкаләсе дөнья күрә. Кайбер китаплары берничә тапкыр басыла. Китап белеме галиме, библиограф Әбрар *Кәримуллин* исәбе буенча, К.Насыйриның үзе исән чагында гына да йөзгә якын китабы басылып чыга. Аның тормыш юлын һәм иҗат эшчәнлеген өйрәнгән Мөхәммәт *Гайнуллин*, беренчеләрдән булып, әдипнең татар телендә дөнья күргән аерым хезмәтләренең библиографик күрсәткечен төзи. 40 исемнән торган бу күрсәткеч мәгърифәтче галимнең тел белеме, әдәбият, арифметика, геометрия, тарих, география, этика, рус теленә өйрәтү, зәркәнчелек һәм слесарьлык эшләре буенча язылган хезмәтләрен үз эченә ала (тулырак кара: *Каюм Насыйриның тормышы һәм иҗаты хакында библиография*). К.Насыйриның вафатыннан соң бик күп кульязмалары һәм

хатлары кала (кара: *Каюм Насыйриның кульязмалары*, *Каюм Насыйриның хатлары*). Алар Казан федераль университеты китапханәсенең *кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә*, ТР Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының *Язма мирас үзәгендә* һәм башка оешмаларда саклана. К.Насыйриның арифметика (математика), астрономия, ботаника, география, геометрия, дин белеме, игенчелек, кулинария, медицина (анатомия, физиология, гигиена), тел белеме, хокук һәм башка фәннәр буенча язган китаплары һәм аерым мәкаләләре татар халкының берничә буыны тарафыннан уку-укыту әсбабы сыйфатында файдаланыла. Аның хезмәтләре бүген дә әһәмиятен җуймый, ул күтәргән мәсьәләләр безнең көннәрдә дә актуаль.

К.Насыйриның энциклопедик масштабтагы эшчәнлеге, беренче чиратта, замандашлары — шәркыятьче галимнәр В.В.Григорьев, В.Д.*Смирнов*, төрки телләр галиме Н.Ф.Катанов тарафыннан югары бәяләнә. Мәгърифәтче галимнең иҗатына аеруча Н.Ф.Катанов зур игътибар бирә, ул аның дистәдән артык әсәренә рецензия яза (кара: *Бәяләмә*, *«Деятель»* газетасы). Язучы Фатих *Әмирхан*: «Иң әүвәл татарларга үзләренең бер телләре бар икәнен белдертер өчен, К.Насыйри «Ләһҗәи татари» вә «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» тәэлиф итүче вә ул ук, иң әүвәл, әсәрләрен татарча яза башлап, һәр язу таныган кеше истифадә итәрлек тарызда ясаучы...», — ди (1908). Тел галиме Җамал *Вәлиди* «Каюм әфәндегә кадәр татар теле дигән бер тел юк иде. Телебезне иң әүвәл бер телгә хисаблап аның да кагыйдәсе барлыгын, башка телләрдән ким булмавын вә хәтта артыклылары булуын дәгъва вә исбат итүче улдыр», — дип яза (1912) һәм «Каюм Насыйри иң элек безнең татарлыгыбызны аңлады һәм аны үзенең әсәрләре илә башкаларга да аңлатмакчы булды», — дип ассызыклый. Ул аны «татар әдибе» дип зурлый. Язучы Галимҗан *Ибраһимов* К.Насыйрины Шәрекътән Гаребкә (Көнбатышка, Европага) юл ясаучы, беренче сукмакны салучы «бөек реформатор» дип атый. Ул: «Каюм бабаның хезмәте гыйлем дөньясы өчен яңа кануннар табып чыгаруда түгел, бәлки бәйнәлмиләл гыйльми мәгълүматны татар халкына башлап бирүдә... Ул бездә Европа гыйлемнәрен беренче популяризатор иде», — ди (1926). Мәшһүр тел галиме-тюрколог Н.К.*Дмитриев* татар галименең фәнни-иҗади эшчәнлеген Италиянең күпкырлы галиме, танылган рәссамы, нәкышьчесе Леонардо да Винчи, беренче бөек рус галиме, табигыять фәннәре белгече, филолог М.В.Ломоносов хезмәтләренә тиңли: «Алар барысы да энциклопедистлар булганнар, нинди дә булса бер фән яки сәнгать кысаларында гына калмаганнар. Алар үзләренең кыска гына гомерләрендә тормышта кирәкле барлык фәннәргә һәм сәнгатьләргә дә нигез салып калдырырга ашыкканнар... Кем булган Ломоносов: физикмы, механикмы, тел белгечеме, әдәбиятчымы? Леонардо да Винчи... һәм Каюм Насыйри кем булган дигән сорауга җавап бирү дә шактый кыен...». Гаяз *Исхакый* аны яңа дәвер әдәбиятының «атасы» дип атый, чөнки ул — рухи-әхлакый һәм идея-эстетик тәрбия биргән күп кенә күренекле әсәрләрне татар укучыларына татар телендә ирештергән шәхес. Татар

укучысының образлы фикерләвен, зәвыгын, туган телнең эчке мөмкинлекләрен истә тотып эш иткән К.Насыйриның тәрҗемә эшчәнлеге дә югары бәяләнә. Шәрекъ халыклары тарихын, ислам гыйлемен өйрәнүче француз шәркыятьче галимәсе Шанталь *Лемерсье-Кельккеже* аның турында болай ди: «Иң әүвәл яктылыкка юлны Каюм Насыйри ачмаса, дөньяда Габдулла Тукай, Шәехзадә Бабич, Галимҗан Ибраһимов, Гаяз Исхакый, Мәҗит Гафури кебек йолдызлар якты яна алмас иде».

***

К.Насыйри тормышының соңгы елларында үз акчасына туган авылы Югары Ширданда мәчет төзетергә уйлый. Авылдашларының икенче Җамигъ мәчет төзүгә рөхсәт сорап мөрәҗәгать иткән үтенечләре буенча 1901 елның 20 июлендә уңай карар кабул ителә. К.Насыйри мәчет төзү чыгымнарын тулаем үз өстенә ала һәм акча бүлеп бирә, әмма бу мәчетне күрү аңа насыйп булмый. Ул 1902 елның 3 сентябрендә (искечә 21 августында) Казанда туганы Мөхәммәтбәдигъ *Хөсәенов* йортында вафат була. Казанның Яңа Татар бистәсе зиратында җирләнә (тулырак кара: *Каюм Насыйриның вафаты*, *Каюм Насыйриның кабере*).

**Тәрҗемәи хәлен һәм тормышын өйрәнү**. К.Насыйриның иҗатын үзе исән вакытта фәнни яктан бәяләүчеләр бик аз була, аларның да күпчелеген рус шәркыятьче галимнәре (И.Ф.Готвальд, В.В.Григорьев, К.Г.*Залеман*, Н.И.Ильминский, Н.Ф.Катанов, О.С.Лебедева, П.П.Масловский, В.В.Радлов, Г.С.Саблуков, В.Д.Смирнов һ.б.) тәшкил итә. К.Насыйри вафатыннан соң «Тәрҗеман» газетасында (1902), татарлар арасында беренче булып, язучы Гаяз Исхакыйның «Габделкаюм әфәнденең вафаты» исемле некрологы басыла. Анда мәгърифәтченең тәрҗәмәи хәле һәм гыйльми эшчәнлеге яктыртыла, татар теле өлкәсендәге хезмәтләре югары бәяләнә.

К.Насыйри вафатына ун ел тулуга бәйле рәвештә татар халкы тарихы турында беренче китаплар күренә башлауга, киң җәмәгатьчелек арасында аның күпкырлы иҗаты һәм тәрҗемәи хәленә карата кызыксыну уяна. Әйтик, 1912 елда «Йолдыз» газетасында тарихчы Габделбари *Батталның* К.Насыйрига багышланган «Телебез» мәкаләсе басыла. Анда мәгърифәтченең халыкка аңлаешлы әдәби тел булдыру юнәлешендә дәвамлы һәм нәтиҗәле эшчәнлек алып баруы турында этрафлы яктыртыла. Мәкалә авторы: «Үз арабыздан чыгып, үз телебезне тергезү нияте белән кулына каләм тоткан затларыбызның иң олугысы Габделкаюм әл-Насыйри абзыйдыр. Аның хезмәтләре татар теленең фән теле була алуына ышандыралар», — дип басым ясый. Шул ук вакытта тарихчы К.Насыйри кебег олуг затка матбугат битләрендә игътибарның булмавына, татар милләте арасында исеменең онытыла баруына ачынып гарьләнә һәм «Шура» журналы мөхәрририятенә бу уңайдан кисәтү ясый. Әлеге вакытлы матбугатның мөхәррире Ризаэтдин *Фәхретдин*, аңа җавап итеп, мәгърифәтче турында бастырырга материал юклыгын әйтә. К.Насыйри турында азмы-күпме мәгълүматлы кешеләр булса, журналга җибәрүләрен үтенә. Нәтиҗәдә, «Шура»ның

1912–1913 елгы саннарында мәгърифәтче галим турында бер дистәдән артык хатирә, биографиясе-шәҗәрәсе, туганнары турында мәкаләләр дөнья күрә (тулырак кара: *Истәлекләр*).

Совет хакимияте чорында, Татарстан Җөмһүрияте барлыкка килгәч, К.Насыйри темасы яңадан күтәрелә. 1922 елның сентябрендә, каты ачлык китергән зыяннан арыну чорында, *Гыйльми үзәк* К.Насыйриның вафатына 20 ел тулу мөнәсәбәте белән аны искә алу чаралары үткәрү турында карар кабул итә. Бу эштә татар теле һәм әдәбияты белгечләре, язучылар, тарихчылар, дәүләт эшлеклеләре Галимҗан Ибраһимов, Шаһит *Әхмәдиев*, Җамал Вәлиди, Хуҗа *Бәдигый*, Гали *Рәхим*, Газиз *Гобәйдуллин* һ.б. актив катнаша. Татарстанда үткәрелгән искә алу чаралары белән беррәттән К.Насыйриның тәрҗемәи хәлен һәм иҗатын өйрәнү эшләре дә алып барыла. Нәтиҗәдә, 1922 елда галимнең мирасы турында *«Каюм Насыйри мәҗмугасы»* исемле беренче фәнни җыентык дөнья күрә. Анда Г.Ибраһимовның К.Насыйриның татар мәгърифәтчелек фикерен үстерүдәге фидакарь хезмәте яктырылган «Каюм Насыйриның тарихи урыны» исемле мәкаләсе аерым игътибарга һәм ихтирамга лаек. Бу мәкалә соңрак К.Насыйри иҗатын өйрәнүче совет галимнәре өчен «үзенчәлекле маяк» булып хезмәт итә (шулай ук кара: *Татар мәгърифәтчелеге*).

1925 елның февралендә, К.Насыйриның тууына 100 ел тулу уңаеннан, Татарстан Җөмһүрияте җитәкчелеге һәм Гыйльми үзәк тарафыннан төрле тантаналы чаралар һәм форумнар уздырыла, бу юнәлештә фәнни-тикшеренү эшләре алып барыла. Әлеге чараларда Фатих Әмирхан, Гыйлемдар *Баембитов*, Хаҗи *Габидуллин*, Галимҗан Ибраһимов, Нәкый *Исәнбәт*, Мөхетдин *Корбангалиев*, Әхмәтһади *Максуди*, Мөхәммәт *Парсин*, Гали Рәхим, Шәйгәрдан *Шәймәрданов* һәм башка галимнәр, дәүләт эшлеклеләре катнаша. Үткәрелгән чаралар нәтиҗәсендә К.Насыйриның тарих, археология һәм этнография буенча кульъязмалары һәм әсәрләре *«Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Мәҗмуга»* (1926) дип аталган җыентыкта дөнья күрә. Бер үк вакытта, 1920 елларда, Татарстан газета-журналларында («Безнең юл», «Вестник научного общества татароведения», «Известия ТатЦИК», «Кызыл Татарстан» һ.б.) К.Насыйриның тәрҗемәи хәле һәм иҗаты турында мәкаләләр һәм хәбәрләр бастырыла.

К.Насыйри шәхесенә 1945 елда, тууына 120 ел тулу уңае белән, кабат әйләнеп кайталар. 1945 елның мартында, Бөек Ватан сугышының соңгы айларында, Мәскәүдә һәм Казанда СССР Фәннәр академиясенең К.Насыйриның тууына 120 ел тулуга багышланган Гыйльми сессиясе уздырыла. Аның эшендә Мәскәүдән — күренекле тел галимнәре: академик С.П.Обнорский, мөхбир әгъзалар Н.К.Дмитриев, М.Ә.Фазлуллин; Казаннан — Җамал *Вәзиева*, Н.И.*Воробьёв*, Мөхәммәт *Гали*, В.М.*Горохов*, Мөхәммәт Гайнуллин, Хәйри *Гыймади*, Латыйф *Җәләй*, Фатих *Мөхәммәдьяров*, Шиһабетдин Рамазанов, Рабига *Хәкимова*, Вәли *Хангилдин*, Хәмит Ярми һ.б. катнаша. Н.К.Дмитриев форумда мәгърифәтчегә багышланган чыгышында болай ди: «Һәр халыкның тормышында, аерым бер кеше тормышындагы кебек,

үз язы була. Каюм Насыйри аны беренчеләрдән булып тоя һәм бөтен иҗатын шуңа багышлый». 1948 елда *«Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары)»* дөнья күрә. Гыйльми сессия материалларында 19 йөздә Россия империясендә, аеруча әдәбият-мәдәният дөньясында барган яңарыш алгарышлары яссылыгында К.Насыйриның татар мәдәниятен, мәгарифен һәм әдәбиятын үстерүгә керткән өлеше яктыртыла, татар халкын әдәби-мәдәни агартудагы роле күрсәтелә. Җыентыкта шулай ук Мөхәммәт Гали һәм Хәмит Ярми тарафыннан К.Насыйриның авылдашларыннан язып алынган *истәлекләр* урнаштырыла.

Бу форумнан соң СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни хезмәткәрләре К.Насыйриның сайланма җыентыкларын әзерләп чыгару эшен дәвам итәләр. 1975 елга, мәгърифәтче әдипнең тууына 150 ел тулганчыга кадәр, берничә «Сайланма әсәрләр» җыентыгы (1945, 1953, 1956 (икенче басмасы, шул ук: *«Әсәрләр»*, 1971), 1974–1975 (ике томда) еллар) дөнья күрә. Шул юбилей уңаеннан Казанда Тел, әдәбият һәм тарих институты, Казан университеты, Казан педагогия институты тарафыннан *«Аталы мәгърифәтче-демократ Каюм Насыйри»* исемле конференция уздырыла. Анда Мәскәүдән тел галиме, төрки телләр белгече А.Н.Кононов, Дагстаннан әдәбият галиме С.Х.*Акбиев*, Казаннан Искәндәр *Абдуллин*, Сәләм *Алишев*, Рашат *Әмирханов*, Ялкын *Әхмәтгалиева*, Дания *Баһаветдинова*, Мәсгуд *Гайнетдинов*, Мөхәммәт Гайнуллин, Мирфатыйх *Зәкиев*, Әбрар Кәримуллин, Хуҗиәхмәт *Мәхмүтов*, Сәвия *Михайлова*, Мидхәт *Мөхәррәмов*, Рәүфә *Уразманова*, Камил *Фасиев*, Фазыл *Фасиев*, Равил *Фәхретдинов*, Вахит *Хаков*, Шифа *Ханбикова*, Әнвәр *Хәйри* һәм башка галимнәр докладлар белән чыгыш ясыйлар.

2003–2006 елларда К.Насыйриның дүрт томлы сайланма әсәрләренең басылып чыгуы галимнең күпкырлы иҗаты белән тулырак танышу мөмкинлеге бирә. Бу басмалар — мәгърифәтченең иң тулы сайланма әсәрләре җыентыгы. Мәсгуд Гайнетдинов һәм Хуҗиәхмәт Мәхмүтов — К.Насыйриның гарәп графикасындагы аерым текстларын гамәлдәге татар язуына күчерүче һәм кереш мәкалә авторлары.

2015 елда К.Насыйриның тууына 190 ел тулу уңаеннан Казанда ТР Фәннәр академиясенең Тарих институты тарафыннан *«Урта һәм югары белем бирү системасында татар телендә укыту: тарих, заманчалык һәм алгарышлар»* исемендә конференция уздырыла. Анда, башлыча, Казан федераль университеты, ТР Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре (Г.Г.*Батыршина*, Р.Х.Шәймәрданов, М.М.Шәкүрова, Р.Р.Хөснетдинов һ.б.) катнаша (шулай ук кара: *Каюм Насыйриның юбилейлары*).

К.Насыйрига багышланган төрле форумнар аның биографиясен һәм күпкырлы иҗатын өйрәнүгә зур этәргеч булып торалар. Бу фәнни-иҗади эшчәнлектә, күргәнебезчә, 20 йөзнең 2 нче яртысы – 21 йөз башында Татарстанның югары уку йортлары һәм фәнни-тикшеренү институтлары, аерым

алганда, Казан университеты (Әбрар Кәримуллин, Мостафа *Ногман*, Резеда *Ганиева*, Мөхәммәт *Мәһдиев*, Ибраһим *Нуруллин*, Альберт Фәтхи, Вахит Хаков, Әлфия *Юсупова* һ.б.), Казан педогогия институты (В.М.*Беркутов*, Таһир *Корбанов*, Якуб *Ханбиков,* Әнвәр *Хуҗиәхмәтов* һ.б.) һәм Тел, әдәбият һәм тарих институты (соңрак Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) (Хатип *Алишев*, Мәсгут Гайнетдинов, Мөхәммәт Гали, Латыйф Җәләй, Мирфатыйх Зәкиев, Фатыйма *Ибраһимова*, Рәмил *Исламов*, Хәлиф *Курбатов*, Хуҗиәхмәт Мәхмүтов, Хисам *Мөхәммәтов*, Шиһабетдин Рамазанов, Резеда *Рәхимова*, Гали *Халит*, Шифа Ханбикова, Вәли Хангилдин, Заһир *Шәйхелисламов*, Хәмит Ярми һ.б.), Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты галимнәре зур активлык күрсәтәләр.

Шулай ук К.Насыйриның юбилейлары уңаеннан «Кызыл Татарстан», «Совет Татарстаны», «Социалистик Татарстан», «Ватаным Татарстан» газеталарында, «Коммунист Татарии», «Татарстан», «Совет әдәбияты», «Казан утлары», «Совет мәктәбе», «Мәгариф» журналларында аның турында төрле эчтәлектәге мәкаләләр дөнья күрә.

К.Насыйри, галим һәм нашир буларак, Татарстанда фәнни-гамәли яктан иң өйрәнелгән әдипләрнең берсе. Галим-әдип эшчәнлегенең төрле тармаклары яктыртылган дистәләгән монография языла, диссертацияләр яклана, йөзләгән мәкалә дөнья күрә. Шуңа да карамастан, энциклопедист галимнең мирасы әле дә өйрәнү-тикшерүне һәм дөньяга чыгаруны таләп итә, чөнки аның кайбер язмалары, мәсәлән, календарьларындагы текстлары гамәлдәге татар язуына күчерелмәгән, кульъязма хәлендәге хезмәтләре дә байтак, шулай ук кайбер әсәрләре (иң күләмлесе — «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият») тулысынча басылмаган.

***Исемен һәм күпкырлы эшчәнлеген мәңгеләштерү***. Бу гамәл Совет чорында башлана. 1925 елда Татарстан хөкүмәте тарафыннан Гыйльми үзәктән килгән тәкъдим нигезендә Казан шәһәрендәге Татар бистәсенең бер урамына (кара: *Каюм Насыйри урамы*), Казан татар укытучылар мәктәбенең дәвамчысы булган Казан татар педагогия техникумына, 2021 елда *Сиксәненче мәктәпкә* К.Насыйри исеме бирелә. Соңрак аның исеме белән Татарстанның башка торак пунктлары урамнары да аталып йөртелә башлый.

Казанда үз өе булмау сәбәпле, К.Насыйрига еш кына яшәү урыннарын алыштырып торырга туры килә (кара: *Каюм Насыйриның яшәү урыннары*). Казанда вафаты алдыннан яшәгән йортта 2002 елда *Каюм Насыйри музее*, аңа кадәр, 1997 елда, Яшел Үзән районының Олы Ачасыр авылында К.Насыйри исемендәге *Архитектура-этнография комплексы* ачыла. 2015 елда «Бөек мәгърифәтче Каюм Насыйриның туган җире — тарихи авыл — Кече Шырданны торгызу» хәйриячелек фонды (оештыручысы — «Акведук» ҖЧҖ директоры А.Н.*Гобәйдуллина*) нигезләнә.

2014 елда Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында *Каюм Насыйри институты*, Россиянең кайбер шәһәрләрендә, Башкортстанда, Әзәрбайҗанда, Казакъстанда,

Кыргызстанда, Үзбәкстанда, Төркиядә һәм башка җирләрдә әлеге институтның үзәкләре ачыла.

1988 елдан Татарстан халык мәгарифен үстерүгә шәхси хезмәтләре белән зур өлеш керткән укытучылар, мәгариф һәм фән хезмәткәрләре, шулай ук педагогик коллективлар ел саен *Каюм Насыйри бүләге* белән бүләкләнәләр.

Шулай ук мәгърифәтченең юбилейлары уңаеннан чыгарылган *Каюм Насыйри маркасында* (1952), Истәлек медалендә (2005), *Юбилей тәңкәсендә* (2025), *«Каюм Насыйри»* драмасында (1945), *«Каюм коесы»* поэмасында (1997) аның исеме мәңгеләштерелә.

К.Насыйрийның фоторәсемнәре булмау сәбәпле, рәссамнар һәм сынчылар аның сурәтен һәм образларын ике дистәдән артык портретларда һәм сыннарда үзләре күзаллаганча яки мәгърифәтчене күреп белгән кешеләр тасвирыннан чыгып мәңгеләштерәләр (тулырак кара: *Портретлар һәм бюстлар*).

*Р.В.Шәйдуллин, Г.И.Каюмова, Ф.Р.Бәдретдинова*